# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында
Антоновка авыл җирлегенең Мартышачий торак пунктында
Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы

2023 елның 30 октябрендәге 2 нче сан

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлегенең Мартышачий торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1.2023 елда Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Антоновка авыл җирлегенең Мартышачий торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 250 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Мартышачий торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Антоновка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Спас муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга ( http:// spasskiy.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Антоновка авыл җирлеге башлыгы
Спас муниципаль районы В.С. Фролов